КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 август г.Казань № 1052

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2022 ел, 30 декабрь, 1464 нче карары белән расланган 2023 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2022 ел, 30 декабрь, 1464 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 22 июль, 733 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2023 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә туңдырма һәм кондитер әйберләре җитештерү буенча фабрика төзү» («Славица» туңдырма фабрикасы» ҖЧЖ, Зеленодольск муниципаль районы).»;

1.10 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

«11) «Татарстан Республикасы территориясендә дүрт криоген ягулык салу пунктын (КриоТЗП), шулай ук техник хезмәт күрсәтү станцияләрен төзү («ГазодТехнология» АЖ, Баулы, Буа, Түбән Кама, Балык Бистәсе муниципаль районнары).»;

1.13 пунктта:

20 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20) «Зеленодольск шәһәрендә Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге адресы буенча урнашкан азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарларның универсаль склады» («Зеленодольск 3 күпләп-бүлү үзәге» ҖЧЖ, Зеленодольск шәһәре);»;

түбәндәге эчтәлекле 35 - 42 пунктчалар өстәргә:

«35) «Татарстан Республикасының Азнакай, Әлмәт, Зәй һәм Түбән Кама муниципаль районнарында сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона булдыру» (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАЖ, Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты, Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты, Зәй муниципаль районы башкарма комитеты, Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты);

36) «Алабуга-2» индустриаль паркы. Нефть химиясе» («Алабуга-2. Нефть химиясе» идарәче компаниясе» ҖЧЖ, Лениногорск муниципаль районы);

37) «Техногород» индустриаль паркы» («Мастер» Кама индустриаль паркы» АЖ, Чаллы шәһәре);

38) «Ростсельмаш» дилерлык үзәге төзелеше» («АРТ» ҖЧЖ, Зеленодольск муниципаль районы);

39) «Лаеш» туристлык территориясен төзү» («Туризм.РФ Татарстан Республикасы» ҖЧЖ, Лаеш муниципаль районы);

40) «Зеленодольск шәһәрендә «ФИЗРА спорт үзәге» физкультура-савыктыру комплексы» спорт инфраструктурасы объектын булдыру («ФИЗРА» ҖЧЖ, Зеленодольск муниципаль районы);

41) «Казан шәһәрендә «ФИЗРА спорт үзәге» физкультура-савыктыру комплексы» спорт инфраструктурасы объектын булдыру («ФИЗРА» ҖЧЖ, Казан шәһәре);

42) «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә «Зеленодольск термалары» термаль комплексын төзү» («Шәһәр термалары» ҖЧЖ, Зеленодольск муниципаль районы).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин